СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ТИМЯШЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ТИМӘШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

Р Е Ш Е Н И Е

К А Р А Р

2022 елның 19 сентябре

№ 19

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Тимәшавылҗирлеге» муниципальберәмлегеСоветының «Җирлесалымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану буенча өстәмә нигезләр турында» 2014 елның 9 июлендәге 22 номерлы карарына (2017 елның 6 июлендәге17номерлы редакциядә) үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, Лениногорск муниципаль районы «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Лениногорск шәһәрпрокуратурасының2022 елның 16 августындагы 02-08-03 номерлы протестын карап, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җирле салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану буенча өстәмә нигезләр турында» 2014 елның 9 июлендәге 22 номерлы карарына (2017 елның 6 июлендәге 178 номерлы редакциядә) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 абзацта «Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 2010 елның 19 августындагы ЯК-7-8/393 номерлы «Недоимканы, пенялар, штрафлар һәм процентларны түләтүгә өметсез дип табылган недоимканы һәм пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычны юкка чыгару тәртибен раслау турында» Боерыгының 6 пункты белән» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 18 августындагы 17 номерлы «Җирле салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану буенча өстәмә нигезләр турында» Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2014 елның 9 июлендәге 22 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында» (2017 елның 6 июлендәге 17 номерлы редакциядә) карары үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Тимәш авылы, Утыз Имәни урамы, 71Д (җирле үзидарә бинасы), Киров урамы, 26 (мәдәният йорты), нефтьүткәргечләр урамы, 20 (Ромашкино РНУ утырышлар залы), Киров урамы, 1А («Ласточка» балалар бакчасы), Лесная урамы, 20, Лесная урамы,33 адреслары буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Тимәш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы, Совет рәисе

Р.М.Сираев